КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 май г.Казань № 583

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл сервисы объектларын Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кушу буенча хезмәт күрсәтүләр бәясен, исемлеген раслау турында» 2017 ел, 7 февраль, 65 нче карары белән расланган Юл сервисы объектларын Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кушу чыгымнарын исәпләп чыгару тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл сервисы объектларын Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кушу буенча хезмәт күрсәтүләр бәясен, исемлеген раслау турында» 2017 ел, 7 февраль, 65 нче карары белән расланган Юл сервисы объектларын Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына кушу чыгымнарын исәпләп чыгару тәртибенә, 2 бүлекнең унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$К_{сз}$ – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына иминият кертемнәре, шул исәптән мәҗбүри пенсия иминиятенә, вакытлыча эшкә сәләтсез булган очракта һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри медицина иминиятенә,

мәҗбүри медицина иминиятенә (иминият кертемнәренең бердәм тарифы) (30 процент), җитештерүдә бәхетсезлек һәм һөнәри авырулар очракларыннан мәҗбүри социаль иминияткә (0,2 процент) иминият кертемнәре күләмен исәпкә ала һәм 1,302гә тигез итеп алына торган коэффициент;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин